Республика Татарстан
СОВЕТ САБИНСКОГО ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Татарстан Республикасы
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САБА ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«02» июнь 2020 ел № 19

Бер мандатлы сайлау округлары
тасвирламасын төгәлләштерү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясына, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы 26 статьясына, яңа йортлар файдалануга кертелүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советының 2015нче елның 30нчы апрелендә кабул ителгән 27нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советына депутатлар сайлауларын үткәрү өчен сайлау округлары схемасын түбәндәгечә төгәлләштерергә:

3 нче сайлау округына Байлар Сабасы ш.т.б. Тынычлык урамын тулысынча кертеп;
7 нче сайлау округына Байлар Сабасы ш.т.б. Шатлык, Тургай, Туганлык, Счастливая, Светлая, Рябиновая, Луговая, Ватан, Балачак, Алмагач, Азатлык урамнарын тулысынча кертеп.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырырга.

3. Карарның үтәлешен тикшерүне үз өстемә алам.

Саба шәһәр җирлеге башлыгы урынбасары Р.М. Хәсәнов